**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Урта Камышлы ав. | **КАРАР**

«09» октябрь 2025 ел | № 8

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге муниципаль милкендә хуҗасыз күчемсез, күчемле һәм бетеп барган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2025 елның 11 сентябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге муниципаль милкенә хуҗасыз күчемсез, күчемле һәм бетеп барган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 11 сентябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге муниципаль милкенә хуҗасыз күчемсез, күчемле һәм бетеп барган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 2.10.4 пунктындагы 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Нурлат муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче В.П. Вафина